КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2026 ел, 28 май

г.Казань

№ 749

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 17 май, 340 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 декабрь, 1363 нче; 2023 ел, 2 май, 550 нче; 2024 ел, 2 март, 112 нче; 2024 ел, 31 октябрь, 944 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Агентлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

14 пунктта татар текстында «Субсидия» сүзен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта «субсидияне» сүзен «субсидия акчасын» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешманың Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә басмага, бастырып чыгаруга һәм таратугага әзерләү чыгымнарын

каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 31 май, 414 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 4 сентябрь, 809 нчы; 2022 ел, 22 август, 873 нче; 2022 ел, 17 декабрь, 1363 нче; 2023 ел, 2 май, 550 нче; 2024 ел, 26 март, 189 нчы; 2024 ел, 9 ноябрь, 970 нче; 2025 ел, 31 октябрь, 891 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Оешманың Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге социаль әһәмиятле әдәбиятны электрон һәм басма төрдә басмага, бастырып чыгаруга һәм таратугага әзерләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Агентлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

54 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

57 пунктта татар текстында «Субсидия» сүзен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

58 пунктта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, Татарстан Республикасында мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, Татарстан Республикасы турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү, мәдәни-агарту программаларын булдыру һәм трансляцияләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 июль, 539 нчы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 683 нче; 2021 ел, 23 сентябрь, 904 нче; 2022 ел, 22 август, 873 нче; 2022 ел, 11 ноябрь, 1198 нче; 2023 ел, 3 май, 550 нче; 2024 ел, 27 март, 189 нчы; 2025 ел, 1 ноябрь, 895 нче; 2025 ел, 22 декабрь, 1104 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендәге оешмаларга Татарстан Республикасының мәгълүмат киңлеген үстерү, шул исәптән аның инфраструктурасын камилләштерү, Татарстан Республикасында мәгълүмат технологияләре базарын үстерү, гражданлык җәмгыятен формалаштыруда массакүләм мәгълүмат чаралары ролен арттыру, Татарстан Республикасы турында, шул исәптән инвестицион җәлеп итүчәнлек турында уңай мәгълүмат формалаштыру һәм аны Россия Федерациясенең барлык территориясе буенча һәм аннан читтә тарату, халыкка бирелә торган мәгълүматның сыйфатын яхшырту һәм оперативлыгын арттыру, Татарстан Республикасындагы ике

дәүләт теленең тигез хокуклылыгын тәэмин итү, мәдәни-агарту программаларын булдыру һәм трансляцияләү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Агентлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

55 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

58 пунктта татар текстында «Субсидия» сүзен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

59 пунктта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Төбәк белән идарә итү үзәген урнаштыру өчен «Диалог Регионы» иҗтимагый элемтәләр һәм коммуникацияләр өлкәсендә цифрлы проектларны үстерү буенча автоном коммерциягә карамаган оешманың түләүсез файдалануга бирелә торган урынны тотуга һәм аңа хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затка субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 5 август, 679 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 август, 873 нче; 2022 ел, 17 декабрь, 1363 нче; 2023 ел, 2 май, 550 нче; 2024 ел, 9 ноябрь, 972 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында Төбәк белән идарә итү үзәген урнаштыру өчен «Диалог Регионы» иҗтимагый элемтәләр һәм коммуникацияләр өлкәсендә цифрлы проектларны үстерү буенча автоном коммерциягә карамаган оешманың түләүсез файдалануга бирелә торган урынны тотуга һәм аңа хезмәт күрсәтүгә бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затка субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Агентлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

17 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 18 пунктында билгеләнгән сайлап алуны уздыру турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән алып заявкаларны кабул итү тәмамлану датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

заявкалар кабул итә башлау датасы җиткәннән соң сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә әлеге Тәртипнең 31 пунктындагы икенче абзацы нигезендә сайлап алуда катнашучыларның заявкага үзгәрешләр кертү хокукы карала торган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.»;

25 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән китерийларга туры килү турында сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе (ирекле формада).»;

39 һәм 40 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

45 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

52 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

55 пунктта татар текстында «Субсидия» сүзен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

56 пунктта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин